Республика Татарстан

САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2019 ел № 36

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга. (1 нче кушымта ).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/saba бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гилманов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Саба шәһәр башкарма комитетының
2019нчы елның “27” февралендә
кабул ителгән 36нчы номерлы карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару Тәртибе.**

I. **Гомуми нигезләмәләр.**

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип).

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

II. **Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы.**

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Саба шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3. Саба шәһәр башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

**III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.**

3.1. Саба шәһәр башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Саба шәһәр башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1. Саба шәһәр башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Саба шәһәр җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә
органнарының муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәтләре өчен
түләүгә факттагы чыгымнары турында
квартал саен мәгълүматлар бастырып
чыгару тәртибенә кушымта

____________20___ел хисап чорына (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел)
Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында
мәгълүматлар

| Хезмәткәрләр категориясе | хисап чоры өчен, хезмәткәрләр саны | хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |